КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 март г.Казань № 252

Казан шәһәре, Жуковский урамы, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

ТАССРның халык артисты, РСФСРның атказанган артисты Исламия Идиятулла кызы Мәхмүтова һәм ТАССРның халык артисты Хәлил Зәки улы Мәхмүтов истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының һәм «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреж-дениесенең И.И.Мәхмүтовага һәм Х.З.Мәхмүтовка Казан шәһәре, Жуковский урамы, 9 нчы йорт адресы буенча бина фасадында рус һәм татар телләрендәге түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«Бу йортта
ТАССРның халык артисткасы,
РСФСРның атказанган артисткасы
Исламия Һидиятулла кызы Мәхмүтова
(2005 – 2019 елларда)
һәм ТАССРның халык артисты
Хәлил Зәки улы Мәхмүтов
(2005 – 2012 елларда)
яшәде
________

В этом доме жили
народная артистка ТАССР,
заслуженная артистка РСФСР
Исламия Идиятулловна Махмутова
(в 2005 – 2019 гг.)
и народный артист ТАССР
Халил Закиевич Махмутов
(в 2005 – 2012 гг.)».

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә мемориаль тактаның балансста тотучысын билгеләүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин